КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 ноябрь г.Казань № 1234

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2019 ел, 31 октябрь, 979 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2019 ел, 31 октябрь, 979 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 14 декабрь, 1134 нче; 2021 ел, 3 июль, 537 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «1 111» саннарын «2 510» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибендә:

1 пунктның икенче абзацында «1 111» саннарын «2 510» саннарына алмаштырырга;

9 пунктның бишенче абзацында «1 111» саннарын «2 510» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 8 пунктындагы дүртенче абзацында «1 111» саннарын «2 510» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин